НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО



# УРМАН КЫЗЫ

ПОЭМА

**Сафиулла ӘҺЛИУЛЛИН**
**Иске Мөъмин авылы,**
**Әсәкәй районы.**

**(Дәвамы. Башы 6 нчы санда).**

**ИКЕНЧЕ БҮЛЕК**

Давыллы көн. Бер чыгасы килми.
Кояш күренгәли аз гына.
Иксез-чиксез урман өсләреннән
Дулкынланып болыт агыла.

Күп тә үтми, дөбер-дөбер килеп
Бозлы яңгыр ява башлады.
Урман хуҗасы да моны күреп,
Өйгә качты, эшен ташлады.

Соңгы вакытларда никтер, эше
Алга бармый бер дә, туктала.
Йокысында начар төшләр күрә,
Гел саташа, тынгы юк аңа.

Онытa алмый үлгән гүзәлкәен,
Кызы өчен бигрәк кайгыра.
Өйләнергә курка, килгән хатын,
Кара да тор, кыздан аера.

Олесяга инде унҗиде яшь.
Бөтен ягы белән өлгергән.
Әтисеннән качып шул авылның
Бер егете белән йөрегән.

Ару гына яугач бозлы яңгыр
Кәтмәгәндә кинәт тукталды.
Кояш чыкты, җылы җилләр искәч,
Тирә-юньдә шулчак тын калды.

Көн җылынгач, шуңа сөенгәндәй,
Алан кошлары да җанланды.
Ашыкмыйча гына, өскә карап,
Хуҗа чыкты, балтасын алды.

Бүген шимбә, бар бит әле аның
Утын ягып мунча ягасы.
Иртәгәсен сөйгән кызы белән,
Хатын каберенә барасы.

Олеся да йокысыннан торып,
Чиләк алып китте җиләккә.
Әтисе артыннан сөенеп калды,
Җитте кызым, диеп, шул яшькә.

Мунча булгач, себеркесен алып
Хуҗа кереп чыкты иң элек.
Мунчадан соң үзен хис итте ул,
Яңа туган ир кебек.

**ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК**

Олеся тыныч,
Иң гүзәл чагы.
Җыенып китте
Ул да мунчага.

Ул да ашыга
Вакыты юк, тар,
Сөйгәне белән
Очрашасы бар.

Егете көтә
Аны аланда.
Икәүләп таңны
Каршылар анда.

Ул быел гына
Мәктәп бетерде.
Шәһәргә барып
Укырга керде.

Мунча юынып
Утыргач чәйгә,
Берәү чиретте
Шулчак тәрәзәгә.

Кызы аңлады
Кемнең килгәнен.
Тышка юнәлде
Алып җиләнен.

Киттеләр алар
Алан ягына.
Йөрсеннәр әйдә
Исән-сау гына.

Бигрәк сөйкемле,
Сихерле алан.
Менә кайдадыр
Пошкырды болан.

Кошлар яңадан
Сайрый башлады.
Егет кулына
Кураен алды.

Уйнап җибәрде
Улда кушылып.
Кызый тыңлады
Бүлмичә тынып.

Яңгырый моңнар
Урман өстендә.
Шулай булсачы
Иде бит көндә.

Безнең дигәнчә
Язылмый язмыш.
Шуңа аңардан
Юк диләр узмыш.

Озакламыйча
Таңы да атыр.
Вакыт та җитә
Өенә кайтыр...

Аның уйларын
Нәрсәдер бүлде.
Күктә гүләгән
Тавыш ишетелде.

Урман өстеннән
Ерак-еракта
Самолет оча
Көнчыгыш якка.

Күп тә үтмәде
Нидер шартлады.
Янгын күренде,
Урман тын калды.

Сокландырырлык
Таң килә атып.
Егет белән кыз
Киттеләр кайтып.

Кызның күзенә
Йокы кермәде.
Сугыш икәнен
Әлегә белмәде.

**(Дәвамы киләсе номерда).**

НАРОДНЫЕ ТРАДИЦИИ И ПРИМЕТЫ

# «Кашлак» открывает половодье

У каждого села есть не только своя история, но и приметы, поверья, традиции. Например, село Асекеево, говорят, основано на этом месте не случайно. На стыке двух рек — Кислы и Усманки — село надежно защищено от северных ветров холмами. Поэтому, даже в зимнюю стужу, метель — в селе затишье и относительно тепло. Раньше приход весны оповещали грачи, которые гнездились на старых ветлах около школ. Теперь этих деревьев почти не осталось. Ну а «барометром» половодья является гора «Кашлак». Это гора находится в западной стороне от села, на ней так называемое «новое» кладбище. Аксакалы давно заметили, как только с горы сходит снег — начинается половодье. Как правило, «большая вода» бывает накануне пятницы. И в этом году «Кашлак» уверенно прогнозирует, что половодье будет на этой неделе.

**Уважаемые читатели, и у ваших родных сел наверняка есть такие истории, традиции, приметы. Поделитесь историей своего родного края.**

**На снимке:** Кинель готовится к половодью.




## «Туган як» — газета твоего родного края!

Продолжается подписка с доставкой со следующего месяца на татарскую культурно-просветительскую газету северо-запада Оренбургской области «Туган як. Родной край». **Газета распространяется в Асекеевском, Бугурусланском, Абдулинском, Северном, Матвеевском и Пономаревском районах. Материалы публикуются на татарском и русском языках.** Концепция редакции — издание народной газеты, отвечающей пожеланиям жителей малых городов и сел.

## Дүрт сәбәп «Туган як»ка язылырга!

**1. Үзегез һәм якташларыгыз, бөтен татар дөньясы, курше районнар тормышы турында хәбәрләр укыйсыз.**
**2. Халкыбызның гөреф-гадәтләрен дин кануннарын өйрәнә аласыз, намаз вакыты күрсәтелә.**
**3. Үзегез язган теләкләрне, киңәшләрне, шигырьләрегезне, хикәяләрегезне бастыра аласыз.**
**4. Татар халык ризыкларын әзерләргә өйрәнәсез.**

**ПОДПИСНОЙ ИНДЕКС — 53167.**

Оформить подписку можно в любом почтовом отделении или у почтальонов. **Лучшие почтальоны будут поощрены материально.** На газету можно подписаться с доставкой с апреля месяца.

**СПРАВКИ ПО ТЕЛЕФОНУ РЕДАКЦИИ: 8(35351)222-81.**


ТУГАН ЯК РОДНОЙ КРАЙ
Расширенное заседание Совета ТНКА
Жыр янгырый, моң янгырый
Подворье быть
Правовой нигилизм наносит вред национальным интересам народа
Беек Тукай аенда очра
Мин татарча сөйләшәм